РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

« 19 » февраль 2021 с. Тюлячи № 64

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарлары
үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «2019-2021 елларга Теләче муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 878 номерлы карары (25.02.2019 ел № 95 карар редакциясендә);

- «2020-2022 елларга Теләче муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 24 декабрендәге 738 номерлы карары (15.01.2020 ел № 10, 27.03.2020 ел № 148, 29.05.2020 ел № 241 карарлар редакциясендә);

- «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 19 маендагы 229 номерлы карары;

- «2019-2020 елларга Теләче муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 31 декабрендәге 763 номерлы карары (26.06.2020 ел № 282 карар редакциясендә);

- «2013-2018 елларга Теләче муниципаль районы мәгарифен үстерү максатчан программасын раслау турында» 2013 елның 13 августындагы 370 номерлы карары (29.12.2017 ел, № 838 карар редакциясендә);

- «2019-2021 елларга Теләче муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану «муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 4 декабрендәге 800 номерлы карары.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин